| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ**

26.10.2018 № 163-од

Казан ш.

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 30 сентябрендәге 125-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасында муниципаль архивлар, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка органнар һәм оешмалар әзерләгән архив белешмәләренә, архив өземтәләренә һәм архив күчермәләренә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 30 сентябрендәге 125-од номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасында муниципаль архивлар, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка органнар һәм оешмалар әзерләгән архив белешмәләренә, архив өземтәләренә һәм архив күчермәләренә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.3.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.1. Комитетның урнашу урыны: 420107, Казан ш., Ново-Песочная ур., 44 нче й.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эш графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе 9.00 алып 17.00 кадәр.

Җомга 9.00 алып 16.00 кадәр.

Көндезге ял 12.00 алып 12.45 кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе 9.00 алып 17.00 кадәр; җомга 9.00 алып 16.00 кадәр; көндезге ял 12.00 алып 12.45 кадәр.

Җәмәгать транспортында килү:

«Сукно бистәсе метро станциясе» тукталышына кадәр:

- автобуслар № 1, 4, 25, 43, 102.
- метро – «Сукно бистәсе» станциясе

«Павлюхин» тукталышына кадәр:

- автобуслар № 4, 25, 43, 71, 102.

«Туфан Миңнуллин» тукталышына кадәр:

- автобуслар № 2, 31, 37, 47, 74.
- троллейбуслар № 6, 8, 12.

Керү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ буенча»;

1.3.4. пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1) Комитет бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында күрсәтмә һәм текст рәвешендәге мәгълүмат бирә торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.3.2, 1.3.3, 1.4, 1.5, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1, 5.2, 5.3 пунктларында бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала»;

1.3.4. пунктчасының 5 абзацында «http://uslugi.tatar.ru» сүзләрен «http://uslugi.tatarstan.ru» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый рәвешендә төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон рәвештә, «бер тәрәзә» принцибы буенча оештыруга вәкаләтләр бирелгән оешма»;

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«КФҮнең ерак урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән КФҮнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы)»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Комитет, шулай ук аның вазыйфаи затлары һәм дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармавына) шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Комитетның, шулай ук аның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының йә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл башкармавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Комитетның вазыйфаи заты карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармавына) шикаять Комитет рәисе исеменә бирелә. Комитет рәисе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармавына) шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылу;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки башкарылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны йә гамәл башкаруны гариза бирүчедән таләп итү;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Комитет, аның вазыйфаи заты җибәргән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән аларның баш тартуы йә мондый төзәтмәләр кертүгә билгеләнгән срокның бозылуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы һәм тәртибе бозылу;

9) әгәр туктатып тору федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү, моңа 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклар керми.

5.3. Комитет, Комитетның вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре, Комитет рәисе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармавына) шикаять Комитетка язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Комитетның рәсми сайтын (http://arhiv.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) порталын (https://www.gosuslugi.ru) кулланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау срогы – аны теркәү көненнән алып унбиш эш көне эчендә. Шикаять Комитетның, аның вазыйфаи затының йә дәүләт граждан хезмәткәренең документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан йә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына бирелгән очракта яки мондый төзәтмәләрне кертүгә билгеләнгән срокның бозылуына бирелгән очракта – аны теркәү көненнән алып биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармавына) шикаять белдерелә торган Комитетның, аның вазыйфаи затының йә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), гариза бирүченең – физик затның яшәү урыны турында белешмәләр йә гариза бирүнең – юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Комитетның, аның вазыйфаи затының йә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл башкармавы) турында белешмәләр;

4) гариза бирүченең Комитет, аның вазыйфаи затын йә дәүләт граждан хезмәткәре карары һәм гамәле (гамәл башкармавы) белән килешмәве өчен нигез булган сәбәпләр.

Гариза бирүче гариза бирүченең сәбәп-дәлилләрен раслый торган документлар йә аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителергә мөмкин:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, түләтелүе Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Гариза бирүчегә, әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында аңлатмалы җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгән җибәрелүе билгеле булган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында Комитет тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм дәүләт хезмәте күрсәтелсен өчен гариза бирүче алга таба башкарырга тиешле гамәлләр хакында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яки аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять чагылышларының булуы ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр аларда булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова